КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 июнь г.Казань № 474

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыга-наклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 377 280 616,33 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);<br>2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);<br>2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);<br>2019 ел – 59 202 986,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 16 900 942,7 мең сум);<br>2020 ел – 49 700 151,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 207 437,8 мең сум).<br>2021 ел – 49 715 025,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 185 416,7 мең сум).<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Еллар буенча бүлеп Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен 100 процентка кадәр үтәү»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 377 280 616,33 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);

2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);

2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);

2019 ел – 59 202 986,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 16 900 942,7 мең сум);

2020 ел – 49 700 151,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 207 437,8 мең сум).

2021 ел – 49 715 025,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 185 416,7 мең сум).

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга мәктәпкәчә белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 52 881 917,82 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;<br>2015 ел – 5 613 039,5 мең сум;<br>2016 ел – 5 944 694,4 мең сум;<br>2017 ел – 5 872 878,8 мең сум;<br>2018 ел – 7 541 911,74 мең сум;<br>2019 ел – 7 633 318,5 мең сум;<br>2020 ел – 7 534 439,4 мең сум;<br>2021 ел – 7 534 439,4 мең сум.<br>2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 52 881 917,82 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;
2015 ел – 5 613 039,5 мең сум;
2016 ел – 5 944 694,4 мең сум;
2017 ел – 5 872 878,8 мең сум;
2018 ел – 7 541 911,74 мең сум;
2019 ел – 7 633 318,5 мең сум;
2020 ел – 7 534 439,4 мең сум;
2021 ел – 7 534 439,4 мең сум.

2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга гомуми белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 158 468 181,04 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;<br>2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;<br>2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;<br>2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;<br>2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;<br>2019 ел – 22 165 602,5 мең сум;<br>2020 ел – 21 264 996,1 мең сум;<br>2021 ел – 21 286 893,7 мең сум.<br>2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның гомуми санының федераль дәүләт белем бирү стандартлары (алга таба – ФДБС) нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санының чагыштырма авырлыгы 100 процентка кадәр арттыру;»;

егерме сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми белем бирүнең төбәк системаларының гомуми санында уку елы нәтиҗәләре буенча түбән белем бирү нәтиҗәләрен күрсәткән гомуми белем бирү оешмаларында һәм начар социаль шартларда эшләүче гомуми белем бирү оешмаларында белем бирүнең сыйфатын күтәрү чаралары эшләнгән һәм тормышка ашырылган гомуми белем бирү оешмаларының төбәк системалары өлешен 2022 елга 76 процентка кадәр арттыру;»;

утыз икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми белем бирүнең муниципаль системаларының гомуми санында уку елы нәтиҗәләре буенча түбән белем бирү нәтиҗәләрен күрсәткән гомуми белем бирү оешмаларында һәм начар социаль шартларда эшләүче гомуми белем бирү оешмаларында белем бирүнең сыйфатын күтәрү чаралары эшләнгән һәм тормышка ашырылган гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль системалары өлешен 2022 елга 100 процент дәрәҗәсендә саклап калу;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе субъектында уку предметларын (предмет өлкәләрен) укыту концепцияләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр өлешен 55 процентка кадәр арттыру;

Дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында (ДХБП) белем бирү нәтиҗәләрен теркәүне, индивидуаль укыту планын карауны, электрон формада белем бирү хезмәтләрен һәм дәүләт хезмәтләрен алу буенча сервисларны үз эченә алган цифрлы мәгариф профиленә керү мөмкинлеген тәэмин итүче «Мәгариф» шәхси кабинеты ачык булган гомуми белем бирү, балалар өчен белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучылар өлешен Татарстан Республикасында күрсәтелгән программалар буенча укучыларның гомуми санында 70 процентка кадәр арттыру,

гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында бер тапкыр тапшырылган беренчел мәгълүматлар нигезендә барлыкка килә торган норматив хокукый актлар белән расланган ведомство һәм статистик хисаплылык документлары өлешен 90 процентка кадәр арттыру»;

ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

8 бүлекчәдә:

бишенче абзацта «2020» саннарын «2022» саннарына алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәктәп китапханәләре фондларын нәфис, тармак, энциклопедик әдәбият, сүзлекләр белән тулыландыру, шул исәптән электрон китапханәләргә керү мөмкинлеге бирү.»;

18 бүлекчәдә:

егерме икенче абзац һәм таблица үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Яңа ФГОС нигезендә конкрет өлкәләрне модернизацияләү концепцияләрен эшләү, мәгарифне үстерү һәм челтәр методик берләшмәләргә ярдәм итү буенча төбәк программаларын гамәлгә ашыру юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләү» чарасы кысаларында 2018 елда – 2019 елларда стажирка үтү урыны («Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе базасында) һәм база мәйданчыклары челтәре (гомуми белем бирү оешмаларында) төзелде, алар территориясендә расланган һөнәри үсеш программалары буенча квалификация күтәрү программаларының бер өлеше гамәлгә ашырыла.

2020-2022 елларда түбәндәге көтелә торган нәтиҗәләр белән стажировка һәм база мәйданчыклары эшчәнлеген дәвам итү планлаштырыла:

1) федераль дәүләт белем бирү стандартларын исәпкә алып гомуми белем программаларын һәм фән, метапредметлы һәм шәхси нәтиҗәләргә ирешү өлешендә уку предметларын укыту концепцияләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләре; федераль дәүләт белем бирү стандартларын исәпкә алып гомуми белем программаларын һәм уку предметларын укыту концепцияләрен (предмет өлкәләрен) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының идарәче хезмәткәрләре (директорлар, директор урынбасарлары); мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт белем бирү стандартларын һәм уку предметларын (предмет өлкәләрен) укыту концепцияләрен гамәлгә кертү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары белгечләре квалификациясен күтәрү;

2) төбәк дәрәҗәсендә кабул ителгән уку предметлары (предмет өлкәләре) концепцияләрен кертү һәм гамәлгә ашыруның «юл картасын» эшләү (эшләп бетерү);

3) предмет фәннәре (предмет өлкәләре) буенча предмет укытучыларының (шул исәптән челтәр методик берләшмәләрнең) иҗтимагый-профессиональ берләшмәләрен төзү һәм аларга ярдәм итү;

4) түбәндәге юнәлешләр буенча иң яхшы төбәк тәҗрибәләрен ачыклау, тасвирлау һәм бәйсез экспертиза:

федераль дәүләт белем бирү стандартларын һәм уку предметларын укытуның концепцияләрен исәпкә алып төп гомуми белем программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту;

федераль дәүләт белем бирү стандартларын һәм уку предметларын укытуның концепцияләрен исәпкә алып төп гомуми белем программаларын гамәлгә ашыруда мәктәп мәгълүмат китапханә системасының (ММКС) катнашуы;

уку предметларын (предмет өлкәләрен) укытуның концепцияләрен исәпкә алып федераль дәүләт белем бирү стандартларының предмет, метапредмет һәм шәхси нәтиҗәләренә ирешү өчен гомуми һәм өстәмә белемне интеграцияләү;

федераль дәүләт белем бирү стандартларын һәм уку предметларын (предмет өлкәләрен) укыту концепцияләрен исәпкә алып төп гомуми белем программаларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча идарәче һәм педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

5) төбәк конкурсы барышында ачыкланган иң яхшы тәҗрибәләрне гавами тәкъдир итү максаты белән төбәкара һәм төбәк чаралар үткәрү;

6) иң яхшы тәҗрибәләр белән бөтенроссия чараларында катнашу.»;

19 бүлекчәдә:

кырык дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017-2019 елларга, шулай ук 2020 – 2022 елларга имин булмаган мәктәпләр үсешенә ярдәм итүче төп чаралар түбәндәгеләр булачак:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«9. Гомуми белем бирү оешмаларына мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү өчен төбәк һәм муниципаль инфраструктура булдыру; гомуми белем бирү оешмаларын һәм әлеге оешмаларның педагогларын консультация һәм тьюторлык белән тәэмин итү.

10. Белем бирүнең сыйфатын күтәрү буенча мәктәп программаларын эшләү.

11. Уку нәтиҗәләре түбән булган мәктәпләр һәм начар социаль шартларда эшләүче мәктәпләр, партнерлар булган мәктәпләр (консультация, методик, оештыру һәм башка төр ярдәм күрсәтү өчен шартлар булган мәгариф оешмалары) белән мәктәпләрнең партнерлык килешүләрен (хезмәттәшлек турында килешүләр) төзү.

12. Проект тематикасы буенча гомуми белем бирү оешмалары арасында тәҗрибә алмашу буенча төбәкара, төбәк, муниципаль чаралар үткәрү.»;

28 бүлекчә исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Заманча мәктәп» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр формалаштыру өчен матди-техник базаны яңарту чаралары; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар)»;

28.1 бүлекчәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 елда Татарстан Республикасында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр формалаштыру өчен матди-техник базаны яңарту чаралары кысаларында авыл районнарының 97 мәктәбе базасында цифрлы һәм гуманитар профильдәге белем бирү үзәкләре төзеләчәк. 2020 елда – 200 авыл мәктәбе базасында, 2021 елда – 250 авыл мәктәбе базасында, 2022 елда – 300 авыл мәктәбе базасында, 2023 елда – 400 авыл мәктәбе базасында, 2024 елда 500 авыл мәктәбе (үсә баручы нәтиҗә белән).»;

28.2 бүлекчәнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 елда Татарстан Республикасының 17 мәгариф оешмасында, 2020 елда – 24 мәктәптә (үсә торган нәтиҗә), 2021 елда – 32 мәктәптә, 2022 елда – 40 мәктәптә, 2023 елда – 47 мәктәптә, 2024 елда 54 мәктәптә яңадан җиһазландыру булачак.

Чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә «Технология» предметы өлкәсе һәм башка предмет өлкәләре эчтәлеге һәм методлары яңартылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өлеше 2024 елга 100 процент тәшкил итәчәк.»;

30 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен гамәлгә кертү; «IT-куб» балалар үсешенең төп үзәкләрен булдыру)

«Мәгариф» милли проекты кысаларында «Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проекты 2024 елга барлык төр һәм дәрәҗәләрдәге белем бирүнең югары сыйфатын һәм үтемлелеген тәэмин итүче заманча һәм куркынычсыз цифрлы белем бирү мохите булдыруга юнәлдерелгән.

«Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә барлык белем бирү оешмаларында укучылар, педагоглар һәм административ-идарә персоналы өчен «цифрлы компетенцияләр» профильләрен булдыру, индивидуаль уку планнарын (программаларын) төзү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән аттестация чараларын узганда онлайн-курслар үтү нәтиҗәләрен исәпләү хокукы белән, административ белем бирү тирәлеген автоматизацияләү; идарә итү һәм процессларны тәэмин итүче; белем бирү сыйфатын бәяләү процедуралары үткәрү планлаштырыла. Белем бирү оешмалары эшчәнлеген оптимальләштерү, мәгариф оешмалары хисапларын электрон рәвешкә күчерү һәм аны автомат рәвештә формалаштыру тәэмин ителәчәк.

Татарстан Республикасында белем бирү сыйфатын күтәрү максатларында барлык белем бирү оешмалары да тотрыклы һәм тиз интернет-элемтә белән тәэмин ителәчәк. Барлык типтагы белем бирү оешмалары рәсми сайтларның мәгълүмати тулылануын һәм функциональ мөмкинлекләрен яңартачак.

«Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында заманча цифрлы белем бирү мохите булдыруны тәэмин итү максатларында 2019 елда Татарстан Республикасында 27 мәгариф оешмасында (12 гомуми белем бирү оешмасы, 14 урта һөнәри белем бирү оешмасы) цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделе кертеләчәк. 2020-2024 елларда әлеге чара 26 белем бирү оешмасы ярдәме белән ел саен дәвам итәчәк.

2024 елга Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында цифрлы белем бирү мохитының максатчан моделе кертеләчәк.

Цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасын кулланып белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү, балаларга өстәмә белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары өлеше 2024 елга гомуми белем бирү оешмаларының 95 процентын тәшкил итәчәк.

«IT-куб» балалар үсешенең төп үзәкләрен булдыру чаралары кысаларында 2021 елда «Әлмәт политехник техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениеесе базасында балаларны цифрлы үстерү үзәген төзү планлаштырыла.

Үзәкне булдыру зарурлыгы заманча дөньяны мәгълүматлаштыру һәм компьютерлаштыру дәрәҗәсен арттыру, шулай ук IT-иҗатка балаларны һәм яшүсмерләрне җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәктәптән тыш эшнең яңа системасын формалаштыру буенча чаралар һәм чаралар комплексын гамәлгә ашыруның актуальлеге белән бәйле.

«IT-куб» IT-иҗат балалар үзәгендә белем бирү хезмәтләре түбәндәге юнәлешләр буенча күрсәтеләчәк:

Python программалаштыру,

Java программалаштыру нигезләре,

мобиль эшләү,

системалы идарә итү,

цифрлы гигиена һәм зур мәгълүматлар белән эш,

C- төр телләрдә программалаштыруның төп күнекмәләре.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру үсеп килүче буын арасында инфраструктура-эчтәлекле дәрәҗәдә цифрлаштыру өлкәсендә компетенцияләрне алга этәрүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк (заманча мәгълүмати технологияләр, ясалма интеллект, зур мәгълүматлар, болыт киңлекләре, программалаштыру һәм цифрлы операцияләр белән идарә итү).»;

31 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Киләчәк укытучысы» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын өзлексез күтәрү үзәкләре һәм мәгариф системасының аккредитация үзәкләре булдыру)

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Киләчәк укытучысы» төбәк проекты 2024 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының кимендә 50 процентын үз эченә алган педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсеш милли системасын гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән.

«Киләчәк укытучысы» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында мәгариф системасы хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын өзлексез үстерү буенча системалы эш оештырылачак һәм квалификация күтәрү программаларының эчтәлеге яңартылачак. Проектның нигезе – педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен өзлексез һәм планлы рәвештә күтәрү өчен шартлар (система) булдыру, шул исәптән заманча цифрлы технологияләрне куллану, һөнәри ассоциацияләрдә, тәҗрибә һәм иң яхшы тәҗрибәләр алмашу программаларында катнашу һәм формалаштыру, эш бирүчеләрне өстәмә һөнәри белем бирүгә җәлеп итү, шул исәптән стажировкалар формасында да.

35 яшькә кадәрге укытучыларның 70 проценты беренче өч елда төрле ярдәм һәм булышлык күрсәтү формаларына җәлеп ителәчәк. Чара практик белгечләрне, шулай ук вузларның профессор-укытучылар составы вәкилләрен алып бару системасына җәлеп итүне күздә тота, бу исә һөнәри осталык дәрәҗәсен һәм белем бирүнең сыйфатын күтәрергә ярдәм итәчәк.

Моннан тыш, педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри үсеш милли системасын үстерү кысаларында гомуми белем һәм өстәмә белем бирү системасындагы педагогик хезмәткәрләрнең 10 процenttан да ким булмаган һөнәри квалификацияне ихтыярый бәйсез бәяләүне үткәрү күздә тотыла. Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектлары белән беррәттән, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләрен аттестацияләү системасы кертеләчәк.

Милли проектның төп күрсәткечләреннән берсе – педагогик хезмәткәрнең (җитәкченең) югары һөнәри статусын, педагогик (идарә) эшчәнлегенең нинди дә булса өлкәсендә аның квалификациясе дәрәҗәсен раслау максаты белән педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм Россия Федерациясе субъектларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын бәяләү үзәген булдыру, педагогик хезмәткәрләрнең өзлексез һөнәри осталык системасын үстерү.

Югарыда аталган үзәкләр булдыру түбәндәге нәтиҗәләрне күздә тота:

шәхсиләштерелгән якын килү нигезендә һөнәри стандартлар нигезендә өстәмә һөнәри белем бирүнең төбәк системасын үстерү;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын үстерүнең яңа моделен гамәлгә кертү;

Татарстан Республикасы педагогларының һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәген төзү һәм эшләтү;

практиканың яңа рәвешләрен, мәгариф оешмаларының челтәр хезмәттәшлеге механизмнарын үз эченә алган җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләрне сыгылмалы күп дәрәҗәле әзерләү буенча тәкъдимнәр эшләү.

2022 елда Татарстан Республикасының федераль конкурс сайлап алуларында катнашуы нәтиҗәсендә һөнәри осталыкны өзлексез күтәрү үзәкләре челтәрен һәм аккредитация үзәген булдыру планлаштырыла. Һөнәри осталыкны өзлексез күтәрү үзәкләрен (кимендә 6 үзәк) югары, һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре буларак оештыру планлаштырыла (Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты, Чаллы дәүләт педагогика университеты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Арча педагогика көллияте, Чаллы педагогика көллияте базасында).

Һөнәри осталык үзәкләре эшчәнлеге педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең квалификациясен өзлексез һәм адреслы арттыру өчен шартлар тудыруга, шул исәптән заманча цифрлы технологияләрне куллану нигезендә дә, һөнәри ассоциацияләрдә катнашу һәм формалаштыру, тәҗрибә һәм иң яхшы тәҗрибәләр алмашу, эш бирүчеләрне һөнәри белем бирүгә җәлеп итүгә йөз тотачак, шул исәптән стажировкалар рәвешендә дә.

Татарстан Республикасы педагогларының мөстәкыйль юридик зат буларак һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәген төзү планлаштырыла.

Формалаштырыла торган үзәкләр челтәре түбәндәгеләрне тәэмин итәчәк:

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри белемнәрен, күнекмәләрен һәм компетенцияләрен актуальләштерү;

педагогик хезмәткәрләрне укыту һәм тәрбия бирүнең яңа формаларын, методларын һәм чараларын, шул исәптән «Мәгариф» милли проекты кысаларында эшләнгән һәм гамәлгә кертелә торган яңа формалар, методлар һәм чараларын куллануга әзерләү;

белем бирү процессына укыту һәм тәрбия бирүнең заманча технологияләрен кертү;

Россия укучыларының белем бирү сыйфатын халыкара тикшеренүләрдә (PISA, TIMSS, PIRLS) катнашуы нәтиҗәләрен яхшырту бурычын исәпкә алып, белем бирү программаларын гамәлгә ашыру барышында белем алучы укучыларның белем сыйфатын күтәрү һәм компетенцияләр формалаштыру.

Нәтиҗәдә Россия педагогларының һәм мәгариф хезмәткәрләренең социаль статусы артачак, бу яшь һәм амбициоз белгечләрне җәлеп итү, Россия мәгарифенең сыйфатын гомумән алганда күтәрү өчен өстәмә стимул булачак.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2025 еллар.

Ярдәмче программа чаралары киселешендә төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук финанслау күләмнәре Ярдәмче программага 1 нче кушымтада күрсәтелгән.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 158 468 181,04 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;
2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;
2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;
2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;
2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;
2019 ел – 22 165 602,5 мең сум;
2020 ел – 21 264 996,1 мең сум;
2021 ел – 21 286 893,7  мең сум.

2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасында:

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «27. | Уку елы нәтиҗәләре буенча түбән белем бирү нәтиҗәләрен күрсәткән гомуми белем бирү оешмаларында һәм начар социаль шартларда эшләүче гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирүнең | - | - | 12 | 0,25 | 35 | 47 | 60 | 68 | 76 | - | - | -»; |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | региональ системаларының гомуми санында белем бирү сыйфатын күтәрү буенча чаралар эшләнгән һәм тормышка ашырыла торган региональ системаларның өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |

31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «31. | гомуми белем бирүнең муниципаль системаларының гомуми санында уку елы нәтиҗәләре буенча түбән белем бирү нәтиҗәләрен күрсәткән гомуми белем бирү оешмаларында һәм начар социаль шартларда эшләүче гомуми белем бирү оешмаларында белем бирүнең сыйфатын күтәрү чаралары эшләнгән һәм тормышка ашырылган гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль системалары өлеше, процент | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 48 – 51 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «48. | Россия Федерациясе субъектында уку предметларын (предмет өлкәләрен) укыту концепцияләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 18 | 34 | 55 | - | - | - |
| 49. | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саны федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санының чагыштырма авырлыгы, процент | - | - | - | - | - | 91 | 96 | 100 | 100 | - | - | - |
| 50. | гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында бер тапкыр тапшырылган | - | - | - | - | - | 3 | 20 | 50 | 70 | 80 | 90 | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | беренчел мәгълүматлар нигезендә барлыкка килә торган норматив хокукый актлар белән расланган ведомство һәм статистик хисаплылык документлары өлеше, процентов | | | | | | | | | | | | |
| 51. | Татарстан Республикасында күрсәтелгән программалар буенча укучыларның гомуми санында дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында (ДХБП) белем бирү нәтиҗәләрен теркәүне, индивидуаль укыту планын карауны, электрон формада белем бирү хезмәтләрен һәм дәүләт хезмәтләрен алу буенча сервисларны үз эченә алган цифрлы мәгариф профиленә керү мөмкинлеген тәэмин итүче «Мәгариф» шәхси кабинеты ачык булган гомуми белем бирү, балалар өчен белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучылар өлеше, процент | - | - | - | - | - | 0 | 15 | 30 | 50 | 60 | 70 | -»; |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга өстәмә белем бирүне, инвалид балаларга белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 2 921 008,61 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 139 168,88 мең сум;<br>2015 ел – 388 317,60 мең сум;<br>2016 ел – 529 023,0 мең сум;<br>2017 ел – 487 193,9 мең сум;<br>2018 ел – 522 533,83 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел – 300 651,0 мең сум;<br>2020 ел – 275 775,7 мең сум;<br>2021 ел – 278 344,7 мең сум.<br>2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәләт һәм уңыш» «белем бирү фонды тәҗрибәсен исәпкә алып Татарстан Республикасының төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның 5 проценттан да ким булмаган өлеше катнашачак программаны тормышка ашыручы балалар һәм яшьләр арасында мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерүнең кимендә бер төбәк үзәген ачу.»;

17 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Һәр баланың уңышы» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү үзәкләрен булдыру; стационар кванториумнар булдыру; балалар үсешенең төп үзәкләрен булдыру; «Кванториум» мобиль технопаркларын булдыру; югары белем бирү оешмалары базасында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы үзәкләр булдыру)

«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләр нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү буенча «Мәгариф» илкүләм проектының максатына ирешүгә юнәлдерелгән. «Һәр баланың уңышы» төбәк проектында «Киләчәккә билет» һәм «Проектория» проектларын гамәлгә ашыру кысаларында сайланган һөнәри компетенцияләр нигезендә баланың башлангыч һөнәри ориентациясе механизмнарын һәм индивидуаль уку планын үстерү каралган. Проектларны гамәлгә ашыруда икътисадның реаль секторы вәкилләре, алдынгы фән эшлеклеләре, уйлап табучылар һәм эшмәкәрләр актив катнашачак. Укучылар югары технологияле тармаклар белән таныша, практик мәсьәләләрне хәл итүдә үзләрен сынап карый, иң кызыклы тармак һәм һөнәрне сайлый алачаклар.

«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты кысаларында балаларга өстәмә белем бирү системасы инфраструктурасын модернизацияләү һәм аның һәркем өчен файдалана алырлык булуын арттыру буенча төбәк чараларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү, 2024 елга балаларга өстәмә белем бирү өчен 333 512 яңа урын булдыру, авыл җирлегендә урнашкан 36 гомуми белем бирү учреждениесендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базаны яңарту күздә тотыла.

Өстәмә белем бирүнең дистанцион формаларын үстерү һәм «Кванториум» мобиль балалар технопаркы кебек проектларны гамәлгә ашыру 2024 елга 450 мең укучыга сыйфатлы өстәмә белем алырга мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән авыл җирендә, кече шәһәрләрдә һәм барырга кыен территорияләрдә яшәүче укучыларга да.

Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен дистанцион технологияләрне куллану тәҗрибәсе киңәя, бу исә сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның кимендә 70 процентын өстәмә белем белән колачларга мөмкинлек бирәчәк.

Илнең технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган балаларның төп күнекмәләрен һәм компетенцияләрен формалаштыру максатларында төбәк проекты кысаларында федераль бюджеттан субсидияләр формасында ярдәм булганда Татарстан Республикасы территориясендә 4 «Кванториум» балалар технопаркын һәм 3тән дә ким булмаган «Кванториум» мобиль технопаркын төзү каралган.

Төбәк проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлык балалар өчен дә гармонияле белем бирү мохите тәэмин ителәчәк, ул Россия Федерациясе халыкларының тарихи һәм милли-мәдәни традицияләренә, рухи-әхлакый кыйммәтләренә, шулай ук формалаштырылган яңа технологик тәртиптә алга китеш юнәлешләре өчен алшартлар булачак.

2020 елда сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү үзәкләрен булдыру чаралары кысаларында Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Сәләт һәм уңыш» белем бирү фонды арасында төзелгән килешү кысаларында сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү республика үзәге булдыру планлаштырыла. Сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү буенча республика үзәге Татарстан Республикасының сәләтле һәм талантлы балалары һәм яшьләре белән югары квалификацияле балаларның һәм яшьләрнең күренекле сәләтләрен һәм сәләтләрен ачыклау, белем бирү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, балаларга һәм яшьләргә индивидуаль продюсерлык ярдәмен тәэмин итү, күренекле сәләтләрен һәм югары квалификацияле яшьләрне алга таба үстерү өчен партнерлык челтәрен үстерү максатыннан оештырыла.

Республика үзәге эшчәнлеге Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең «Перспектива» интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм тормышка ашыру концепциясе һәм «Казан ачык талантлар университеты 2.0» КБАО гомуми координациясе нигезендә алып барылачак, ул Фәнни-эксперт советы аша фәнни-эксперт ярдәм күрсәтүне һәм «Фән», «Мәдәният һәм сәнгать», «Спорт» юнәлешләре буенча белем бирү программаларын эшләүне тәэмин итә. Белем бирү программаларын оештыру һәм үткәрү өчен төп мәйданчык булып тиешле уку-лаборатория базасы һәм милек комплексы белән «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Олимпиада үзәге» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең «Дуслык» сәламәтләндерү-белем бирү комплексы чыгыш ясаячак.

Стационар кванториумнар булдыру чаралары кысаларында 2020 елда Казан шәһәрендә «Кванториум» балалар технопаркын, 2021 елда «Алабуга» МИЗ да «Кванториум» балалар технопаркын төзү планлаштырыла. Кванториумнар дәүләт-шәхси партнерлык принциплары нигезендә фән, бизнес һәм дәүләтне берләштерү

максатларында балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирүнең яңа моделен гамәлгә кертү өчен төзеләчәк.

Казан шәһәренең «Кванториум» балалар технопаркында балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру автоквантум, аэроквантум, биоквантум, геоквантум, тулыландырылган чынбарлык, IT-квантум, космоквантум, наноквантум, нейроквантум, промдизайн, робоквантум, энергджиквантум кебек квантумлар буенча гамәлгә ашырылачак.

Квантумнарны гамәлгә ашыру Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ, Казан милли тикшеренү технология университеты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты, Казан дәүләт энергетика университеты, Казан дәүләт медицина университеты, Казан дәүләт аграр университеты, Иннополис Университеты кебек интеллектуаль партнерлар белән хезмәттәшлек нигезендә гамәлгә ашырылачак. Технопарк эшчәнлегенә шулай ук индустриаль партнерлар җәлеп ителәчәк: «Казан вертолет заводы» ААҖ, «С.П.Горбунова исемендәге КАПО» ААҖ, «КМПО» ААҖ, «Казаньоргсинтез» ААҖ, «Казан синтетик каучук заводы» ААҖ, «Татэнерго» ААҖ, «Сетевая компания» ААҖ, ICL-КПО ВС компанияләр төркеме.

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона базасында «Кванториум» балалар технопаркы «Стандарт» моделе буенча ачылачак һәм квантлардан торачак: hi-tech, автоквантум, биоквантум, энергджиквантум, промробоквантум, IT-квантум. Һәр квантум Ford Sollers, Saria bio-industries, Umatex Rosatom, Kastamonu һ. б. кебек идарәче компания резидентлары кул астында төзелә.

Кванториумнар елына 800 дән дә ким булмаган баланы колачлауны һәм бианларның гомуми мәйданы кимендә 1000 кв. метр булачак дип фаразлана. Чараны гамәлгә ашыру «Өстәмә белем бирү белән колачланган 5 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалар өлеше» күрсәткечен 2024 елга 80 процентка җиткерергә ярдәм итәчәк.

2020 елда мобиль кванториумнар булдыру чаралары кысаларында Чаллы шәһәрендә «Кванториум» балалар технопаркы мәйданчыгында мобиль технопарк төзеләчәк. Балаларны инженерлык юнәлешендәге программаларга өйрәтә торган мобиль технопарк, шулай ук техник юнәлешле мәктәп һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре педагогларын өстәмә әзерләү һәм практик юнәлешле укытуны гамәлгә ашыручы мобиль технопарк транспорт станциясе базасында оештырылачак. 2020 елда белем бирү юнәлешләре исемлеге: VR, «Промдизайн», «Геоквантум», «Аэроквантум», «Робоквантум», «IT-квантум», «Хайтек».

2022 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы базасында 2021 елда төзелгән Кванториум нигезендә мобиль кванториум ачылачак. Татарстан Республикасы районнарында инженерлык фикерләвен иртә үстерү максатларында 2022 елда Алабуга шәһәрендә стационар кванториум базасында мобиль кванториум булдыру планлаштырыла. Мобиль комплекс эшчәнлеге зонасында Мамадыш, Менделеевск, Тукай, Түбән Кама, Зәй һәм Минзәлә районнары булачак.

Югары белем бирү оешмалары базасында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы үзәкләр булдыру чарасы кысаларында Казан (Идел буе) федераль университеты (2020 ел), «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном белем бирү учреждениесе (2021 ел), «Казан милли тикшеренү техник университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном белем бирү учреждениесе (2022 ел) базасында үзәкләр булдыру планлаштырыла

Үзәкне төзү максатларына түбәндәгеләр керә: югары һөнәри белем оешмалары базасында биоген инженерия, машина белән фикерләү, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык өлкәсендә 18 яшькә кадәрге балаларның сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү нәтиҗәле системасын формалаштыру, югарыда аталган өлкәләрдә балаларны фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлеккә җәлеп итү.

Үзәкләрнең эшләве мөмкинлек бирәчәк:

1. 18 яшькә кадәрге балалар арасында максатчан һөнәри юнәлеш бирү эшен алып барырга;

2. Күрсәтелгән өлкәләрдә сәләт һәм талантлар күрсәткән балалар өчен өстәмә белем бирү мохитен тәэмин итәргә;

3. Фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлек үсеше өчен уңайлы шартлар тудырырга;

4. WorldSkills таләпләрен һәм әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып, әлеге компетенцияләр буенча балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашырырга;

5. Үзәк базасында хезмәт базары таләпләре һәм тыңлаучыларның теләкләре белән билгеләнгән индивидуаль белем бирү траекториясен тормышка ашырырга.

Үзәкләр булдыру нәтиҗәсе талантлы яшьләр арасында фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлеккә ярдәм итү һәм потенциалны үстерү булачак.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 2 921 008,61 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 139 168,88 мең сум;
2015 ел – 388 317,60 мең сум;
2016 ел – 529 023,0 мең сум;
2017 ел – 487 193,9 мең сум;
2018 ел – 522 533,83 мең сум;
2019 ел – 300 651,0 мең сум;
2020 ел – 275 775,7 мең сум;
2021 ел – 278 344,7 мең сум.

2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

ярдәмче программаның 5 бүлегендәге таблицага түбәндәге эчтәлекле 35 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «35. | Татарстан Республикасының төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның 5 проценттан да ким булмаган күләме катнашкан «Сәләт һәм уңыш» белем бирү фонды тәҗрибәсен исәпкә алып, программаларны тормышка ашыручы балалар һәм яшьләр арасында сәләтлелекне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү төбәк үзәкләре саны, берәмлек | - | - | - | - | - | 0 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | -»; |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга һөнәр белеме һәм югары уку йортларын тәмамлаганнан соң белем бирүне үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

Ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 64 940 619,91 мең сум, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 4 500 128,27 мең сум;<br>2015 ел – 4 772 185,2 мең сум;<br>2016 ел – 4 939 069,8 мең сум;<br>2017 ел – 5 797 077,8 мең сум;<br>2018 ел – 20 004 491,14 мең сум;<br>2019 ел – 11 486 462,8 мең сум;<br>2020 ел – 6 714 254,6 мең сум;<br>2021 ел – 6 726 950,3 мең сум.<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программана тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (алга таба – СМЧ) затлар тарафыннан урта һөнәри белем алу өчен шартлар тәэмин ителгән урта һөнәри белем бирү оешмалары санын, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, 35 берәмлеккә кадәр арттыру.»;

ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

кырык дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Тиешле әзерлек юнәлешләре буенча ресурс укыту-методик үзәкләрен булдыру («Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Норматив-методик базаны эшләү һәм инициативалы проектларга ярдәм итү юлы белән сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә урта һөнәри һәм югары белем алу өчен шартлар тудыру» чарасын финанслашу).»;

кырык сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкуренциягә сәләтен арттыру)» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән урта һөнәри белем бирү системасында яңа белем бирү технологияләрен һәм алдынгы профессиональ әзерлек рәвешләрен эшләү һәм тарату);»;

9 бүлекчәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы территориаль үсеше максатларыннан чыгып гамәли квалификацияләрнең күпфункцияле үзәкләрен һәм әзерләү профилләре буенча ресурс үзәкләрен булдыру (шул исәптән 1.2 «Урта һөнәри һәм югары белем бирү системаларында яңа белем бирү технологияләрен, белем бирү процессын оештыру формаларын эшләү һәм тарату» чарасын; 5.4 «2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» дәүләт программасының 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Мәгариф системасын үстерү һәм мониторинглау өлкәсендә инновацияләргә ярдәм итү» чарасын финанслашу, Россия Федерациясе субъектларында инвалидларга инклюзив һөнәри белем бирүнең төбәк системасына ярдәм итүче база һөнәри белем бирү оешмалары булдыру);

20 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Тиешле әзерлек юнәлешләре буенча ресурслы укыту-методик үзәкләр булдыру («Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Норматив-методик базасын эшләү һәм инициативалы проектларга ярдәм итү юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә урта һөнәри белем алу өчен шартлар тудыру» чарасын финанслашу

Татарстан Республикасында 2016/2017 уку елында мәктәпләрдә 1,6 мең инвалид һәм СМЧ затлар укуларын тәмамлады, алар арасында зур өлешне терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, ишетү һәм акыл үсеше зыян күргән балалар тәшкил итә. Әлеге чыгарылыш сыйныф укучыларының һөнәри ниятләрен өйрәнү нәтиҗәләре буенча, сораштырылучыларның чиреге диярлек төзелеш юнәлешендәге белгечлек

һәм һөнәрләрне сайлаган. Шуның белән бергә 1,4 меңгә якын инвалид һәм СМЧ затлар гына Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмаларында белем ала (шуларның яртысыннан артыгы – төзелеш һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендәге белгечлекләр һәм һөнәрләр буенча).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү системасында инклюзив якын килүне гамәлгә ашыру проблемасы инвалид һәм СМЧ затлар тарафыннан һөнәри белем алуга ихтыяҗ арту яктылыгында инклюзив һөнәри белем бирүне кирәкле ресурслар белән тәэмин итү булмау шартларында бик актуаль булып тора. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә инклюзив һөнәри белем бирү буенча ресурс укыту-методик үзәк булдыру (алга таба – РУМҮ) зур актуальлек ала.

РУМҮ булдыруның максаты – махсус ихтыяҗлары булган һәм социомәдәни адаптациягә мохтаҗ булган яшьләрне һәм өлкәннәрне укыту һәм һөнәри әзерләү өчен кирәкле шартларны тәэмин итүче төбәк стратегиясен тормышка ашыру өчен профессиональ белем бирү оешмасы ресурслары концентрациясе аша инвалидларның һәм СМЧ затларга һәркем алырлык сыйфатлы һөнәри белем бирү һәм аларның махсус белем алу ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

РУМҮ төзү бурычлары түбәндәгеләр:

инклюзив якын килү контекстында СМЧ укучылар һәм инвалидлар өчен яңа белем бирү программаларын (шул исәптән җайлаштырылган белем бирү дисциплиналарын), инновацион белем бирү технологияләрен һәм махсус белем бирү хезмәтләре күрсәтү модельләрен эшләү, апробацияләү һәм гамәлгә кертү, дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә кертүне дә кертеп;

инвалидларга һәм СМЧ затларга инклюзив һөнәри белем бирү төбәк системасына ярдәм итү, төбәктә инклюзив процессларны мәгълүмати тәэмин итү, төбәкнгең һөнәри белем бирү оешмаларының (алга таба – ҺБО), РУМҮ эш тәҗрибәсен гомумиләштерү, гамәлгә ашырыла торган инклюзив практикалар, методикалар һәм алымнар турында мәгълүмат әзерләү;

РУМҮдә төбәк икътисады өчен кирәкле һәм перспективалы белгечлекләр буенча мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны һәм СМЧ затларны укытуның иң яхшы практикасын формалаштыру, инвалидлар һәм СМЧ затлар тарафыннан урта һөнәри белем алу, аларны социальләштерү һәм адаптацияләү өчен кирәкле оптималь шартлар тудыру;

инклюзив концепцияне гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмаларының, инвалидларның иҗтимагый оешмаларының, потенциаль кадрлар заказчыларының һәм инвалидларның тормыш шартларын җайга салу мәсьәләләрен хәл итүдә катнашучы башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

Куелган бурычларны хәл итү өчен түбәндәге юнәлешләр буенча программа чаралары комплексын гамәлгә ашыру планлаштырыла:

1. СМЧ затлар өчен ҺБО архитектурасына керә алуны оештыру;

2. СМЧ кешеләр өчен өстәмә һөнәри һәм гомуми белем бирү программаларын эшләү, шул исәптән электрон һәм дистанцион укытудан файдаланып;

3. Җиһазлар белән тәэмин итү, шул исәптән махсус уку, тернәкләндерү, компьютер җиһазлары сатып алу, инвалидлар һәм СМЧ затларның махсус белемгә ихтыяҗлары һәм шәхси мөмкинлекләре төрлелеген исәпкә алып;

4. СМЧ затлар өчен һөнәри белем алу мөмкинлеген мәгълүмати-техник тәэмин итү;

5. СМЧ затларны дистанцион укыту;

6. Инклюзив һөнәри белем темасы буенча педагогик һәм идарә кадрларының квалификациясен күтәрү, яңадан әзерләү һәм стажировкалау;

7. СМЧ балалар белән һөнәри юнәлеш бирү эше.

Ишетү сәләте начар булган затлар өчен «Төзелеш» юнәлеше буенча 08.02.01 «Биналар һәм корылмаларны төзү һәм эксплуатацияләү», 08.01.08 «Бизәкләү төзү эшләре остасы», 08.01.06 «Коры төзелеш остасы», 05.02.12 «Бакча-парк һәм ландшафт төзелеше» белгечлекләре буенча инклюзив һөнәри белем бирүне гамәлгә ашыручы һөнәри оешма булып Казан төзелеш көллияте тора.

Әлеге белгечлекләр/һөнәрләр ТОП-50 һәм ТОП-РЕГИОН буенча иң кирәкле һәм перспективалы белгечлекләр/һөнәрләр исемлегенә керә, әлеге әзерлек юнәлешләре буенча чыгарылыш сыйныф укучыларын эшкә урнаштыру мөмкинлеген бирә.

РУМҮ булдыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре:

инвалидлар һәм СМЧ затлар һәркем алырлык, сыйфатлы урта һөнәри белем алсын өчен психологик-педагогик шартлар тудыру, шул исәптән заманча дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, һәм аларның һөнәри осталык конкурсларында катнашу өчен;

инклюзив белем бирү өчен заманча техник чаралар һәм махсус җиһазлар бердәм комплексына берләштерү;

инклюзив белемнең укыту-программа һәм методик тәэмин итү банкын булдыру;

инклюзив белем бирү өлкәсендә Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү педагогик хезмәткәрләренең һәм белгечләренең компетентлыгын арттыру;

һөнәри белем бирү оешмаларының, эш бирүче предприятиеләрнең, социаль һәм иҗтимагый оешмаларның системалы хезмәттәшлеге механизмнарын булдыру.

«2019 елда «Бөгелмә төзелеш-техник көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында ресурс укыту-методик үзәге төзеләчәк, анда нигездә Татарстан Республикасы икътисадының тиешле ихтыяҗларына тулысынча туры килә торган сәнәгать һәм төзелеш өлкәсендә белгечлек буенча укыту планлаштырыла.

2019 елда Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре:

1. Инвалидларны һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларны «Төзелеш» юнәлеше буенча укыту өчен җайлаштырылган төп һөнәри белем бирү программалары (алга таба – ОПОП) апробацияләнде.

2. Инвалидларны һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларны «Төзелеш» юнәлеше буенча белем бирүне оештыруның нәтиҗәле

педагогик технологияләре, продуктив методлары һәм формалары кейсы эшләнелде һәм практикада сынап каралды.

3. «Төзелеш» юнәлеше буенча һөнәрләр/белгечлекләр буенча дистанцион курслар үткәрү өчен укыту-методик материаллар базасы һәм яңа интерактив модульләр булдырылды.

4. Инвалидлыгы һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларга дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып белем бирүгә ярдәм итү өчен «Интернет» челтәрендә бүлеп бирелгән белем бирү сегменты тутырылды.

5. «Абилимпикс» инвалидлыгы булган кешеләр өчен (маляр эше, столяр эше, кондитер эше) һөнәри осталык төбәк чемпионатының 3 компетенциясе буенча ярышлар мәйданчыклары әзерләнгән.

6. Инвалидлыклары һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне эшкә урнаштыруга һәм эш урыннарында «Төзелеш» юнәлеше буенча беркетүгә ярдәм итү программасы формалаштырылды.

2020 – 2022 елларда «Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт аграр һөнәри белем бирү учреждениесе базасында урта һөнәри белем бирү системасында (алга таба – урта һөнәри белем бирү) инвалидларны һәм СМЧ затларны норматив-методик базаны эшләү һәм инициативалы проектларга ярдәм итү юлы белән укыту буенча РУМҮ оештырыла. Ул һөнәри белем бирү оешмасының структур бүлекчәсе буларак барлыкка киләчәк. Эшчәнлекнең максаты – республиканың инвалидларга һәм СМЧ кешеләргә урта һөнәри белем бирү, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларының белем бирү, инновацион, методик эшчәнлеген камилләштерү юлы белән инклюзив һөнәри белем бирү системасы үсешен методик һәм эксперт белән тәэмин итү.

«Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт аграр һөнәри белем бирү учреждениесе базасында РУМҮ төзү төп һөнәри белем бирү программалары, контроль-үлчәү материаллары һәм бәяләү чаралар фондлары, эш бирүчеләр һәм инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре катнашында инвалид һәм СМЧ укучыларны әзерләү методикалары һәм технологияләре эшләү һәм актуальләштерү мөмкинлеге бирәчәк. Шулай ук конкурс биремнәрен, контроль-бәяләү чараларын, «Абилимпикс» һөнәри осталык конкурсларының эш урынын җиһазландыру таләпләрен эшләү, актуальләштерү буенча эш башкарылачак.

2021 – 2022 елларда Урта һөнәри белем бирү РУМҮ эшчәнлегенең дәвамы булып профориентация, һөнәри белем бирү, эшкә урнашуга кадәр төрле нозологик төркемнәр инвалидлыгы һәм СМЧ кешеләрне инклюзив һөнәри белем бирү мәсьәләләре буенча методик рекомендацияләр төзү, шулай ук төрле нозологик төркем укучылары өчен һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиһазлар исемлеген формалаштыру торачак. Урта һөнәри белем бирү РУМҮ тарафыннан оештырылган һөнәри белем бирү системасының педагогик хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курслары инклюзив һөнәри белем бирү өлкәсендә аларның һөнәри компетенцияләренең үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. Урта һөнәри белем бирү РУМҮ банкларын, инклюзив һөнәри белем бирү һәм укыту методикаларын һәм технологияләрен формалаштыру һәм алып бару

республикада инклюзив һөнәри белем бирүнең тотрыклы үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2025 еллар.

Ярдәмче программа чаралары киселешендә төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук финанслау күләмнәре ярдәмче программага 1 нче кушымтада күрсәтелгән.»;

21 бүлекчәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем алу мөмкинлеген тәэмин итү (инвалидларга инклюзив һөнәри белем бирүнең төбәк системасына ярдәм итә торган база һөнәри белем бирү оешмалары булдыру буенча чараларны финанслашу)»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2018 елда инвалидларның һөнәри белем бирү төбәк инклюзив һөнәри белем бирү системасына ярдәм итүне тәэмин итүче база һөнәри белем бирү оешмасы итеп «Чаллы педагогика көллияте» ДАҺБУ билгеләнде».

2020 елда «Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында инвалидларга һәм СМЧ затларга инклюзив урта һөнәри белем бирү төбәк системалары (алга таба – һөнәри белем бирү база оешмасы) эшләвен тәэмин итә торган база һөнәри белем бирү оешмасы төзеләчәк.

Аның эшчәнлегенең төп юнәлешләре түбәндәгеләр булачак:

һөнәри юнәлеш бирү, инвалидларны һәм СМЧ затларны, аларның сәләтләрен һәм һәвәслекләрен исәпкә алып, диагностикалау һәм консультация бирү;

урта һөнәри белем бирү, һөнәри белем бирү программалары, инвалидлар һәм СМЧ кешеләре өчен өстәмә һөнәри программалар шартларын һәм тормышка ашыруны тәэмин итү;

һөнәри белем алу һәм алга таба эшкә урнашуда ярдәм итү, аларның һөнәри һәм социаль җайлашуы процессында инвалидларны һәм СМЧ затларны тәэмин итүне оештыру.

База һөнәри белем бирү оешмасын төзү нәтиҗәсендә, республикада, тулаем алганда, инвалидлар һәм СМЧ затлар тарафыннан һөнәри белем алуның архитектур һәм мәгълүмати яктан ачыклыгы дәрәҗәсе артачак. Дистанцион белем бирү технологияләрен куллану, электрон укыту өчен тернәкләндерү һәм компьютер җиһазларын үз эченә алган матди-техник һәм методик шартлар тудырылачак. Шулай ук уку-җитештерү остаханәләрендә һәм өч нотологик төркем өчен лабораторияләрдә (күрү сәләтен бозу, ишетү сәләтен бозу, терәк-хәрәкәт аппаратын бозу) эш урыннары җиһазландырылачак.»;

22 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. «Яшь профессионаллар» төбәк проектын тормышка ашыру («Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында һөнәри белем бирүнең конкурентлылык сәләтен арттыру) (шул исәптән урта һөнәри белем бирү системасында яңа белем бирү технологияләре һәм алдынгы профессиональ әзерлек формалары эшләү һәм тарату)

«Яшь профессионаллар (һөнәри белем бирүнең конкуренциягә сәләтен арттыру)» төбәк проекты һөнәри белем бирүне модернизацияләүгә юнәлдерелгән, шул исәптән адаптив, гамәли юнәлешле һәм сыгылмалы белем бирү программаларын гамәлгә кертү юлы белән.

Әлеге проектны гамәлгә ашыру кысаларында 2019 елда Казанда «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты уздырылачак.

«Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында 2019 елда алдынгы һөнәри әзерлек үзәге һәм компетенцияләрнең берсе буенча заманча таләпләр нигезендә җиһазландырылган 3 остаханә төзеләчәк, шул исәптән «Яшь профессионаллар (Ворлдскиллс Россия)» һөнәр берлекләрен һәм эшче кадрларны үстерү агентлыгы» берлеге алга таба – Берлек) тәҗрибәсен исәпкә алып, демонстрацион имтихан тапшыру өчен.

Татарстан Республикасында, программаларның 6 айдан артмаган дәвамлылыгын исәпкә алып, Ворлдскиллс стандартларына туры килә торган дәрәҗәдә, иң кирәкле һәм перспективалы һөнәрләр буенча һөнәри белем бирү программалары гамәлгә кертеләчәк.

2024 ел ахырына Татарстан Республикасының 42 һөнәри белем бирү оешмасында дәүләт йомгаклау аттестациясе һәм укучыларның арадаш аттестациясе Берлек тәҗрибәсен исәпкә алып демонстрацион имтихан формасында үткәреләчәк, бу Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә һөнәри белем дәрәҗәсен сизелерлек арттырырга ярдәм итәчәк.

2024 елның 31 декабренә кадәр кимендә 315 укытучы (җитештерү буенча укыту осталары) Берлек тәҗрибәсенә нигезләнгән программалар буенча квалификация күтәрү узачак, шулардан кимендә 64 укытучы (җитештерү буенча укыту осталары) Ворлдскиллс экспертлары сыйфатында сертификацияләнгән.

Урта һөнәри белем бирү системасында урта һөнәри белем бирү системасында остазлык методологиясе булдыру, шул исәптән әлеге эшчәнлеккә практик белгечләрне җәлеп итү юлы белән дә, актив үсеш алачак. 2024 ел ахырына иҗтимагый-эшлекле берләшмәләрне җәлеп итүнең максатчан моделен гамәлгә кертү һәм эш бирүчеләр вәкилләренең һөнәри белем бирү оешмалары белән идарә итүдә катнашуы планлаштырыла, шул исәптән һөнәри белем бирү оешмалары белән идарә итү коллегиаль органнарында вәкил булу аша һәм белем бирү программаларын яңартуда катнашу аша.»;

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 64 940 619,91 мең сум, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 4 500 128,27 мең сум;

2015 ел – 4 772 185,2 мең сум;

2016 ел – 4 939 069,8 мең сум;

2017 ел – 5 797 077,8 мең сум;

2018 ел – 20 004 491,14 мең сум;

2019 ел – 11 486 462,8 мең сум;

2020 ел – 6 714 254,6 мең сум;

2021 ел – 6 726 950,3 мең сум.

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасында:

63 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «63. | Инвалидлар һәм сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, урта һөнәри белем алсын өчен шартлар тудырылган урта һөнәри белем бирү оешмалары саны, данә | - | - | - | - | - | 34 | 35 | 35 | 35 | - | - | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 69 – 71 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «69. | Урта һөнәри белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид һәм СМЧ кешеләр, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, мондый оешмаларның урта һөнәри белем бирү оешмалары белән тәэмин ителгән өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 37 | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 |
| 70. | Урта һөнәри белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгән инвалидлар өлеше (узган ел белән чагыштырганда), процент | - | - | - | 101 | 102 | 103 | 105 | 107 | 109 | 111 | 113 | 115 | 117 |
| 71. | Академик җитешмәү аркасында төшеп калган урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучы инвалидлар арасыннан студентлар өлеше, процент | - | - | - | 9 | 8 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7»; |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» ярдәмче программада:

ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме | Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 1 047 587,12 мең сум тәшкил итә шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 92 476,45 мең сум;<br>2015 ел – 86 119,2 мең сум;<br>2016 ел – 93 902,1 мең сум;<br>2017 ел – 174 622,7 мең сум;<br>2018 ел – 186 907,07 мең сум;<br>2019 ел – 141 967,6 мең сум;<br>2020 ел – 135 573,1 мең сум;<br>2021 ел – 136 018,9 мең сум.<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 1 047 587,12 мең сум тәшкил итә шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 92 476,45 мең сум;
2015 ел – 86 119,2 мең сум;
2016 ел – 93 902,1 мең сум;
2017 ел – 174 622,7 мең сум;
2018 ел – 186 907,07 мең сум;
2019 ел – 141 967,6 мең сум;
2020 ел – 135 573,1 мең сум;
2021 ел – 136 018,9 мең сум.

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

ярдәмче программага кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләме | Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 3 810 674,92 мең сум тәшкил итә шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 410 683,3 мең сум;<br>2015 ел – 385 627,7 мең сум;<br>2016 ел – 383 678,3 мең сум;<br>2017 ел – 425 799,7 мең сум;<br>2018 ел – 496 208,22 мең сум;<br>2019 ел – 574 041,5 мең сум;<br>2020 ел – 567 674,9 мең сум;<br>2021 ел – 566 961,3 мең сум.<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 3 810 674,92 мең сум тәшкил итә шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 410 683,3 мең сум;
2015 ел – 385 627,7 мең сум;
2016 ел – 383 678,3 мең сум;
2017 ел – 425 799,7 мең сум;
2018 ел – 496 208,22 мең сум;
2019 ел – 574 041,5 мең сум;
2020 ел – 567 674,9 мең сум;
2021 ел – 566 961,3 мең сум.

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

ярдәмче программага кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 93 210 626,91 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 3 276 380,3мең сум;<br>2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;<br>2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;<br>2017 ел – 8 141 860,8 8 мең сум;<br>2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;<br>2019 ел – 16 900 942,7 мең сум;<br>2020 ел – 13 207 437,8 мең сум;<br>2021 ел – 13 185 416,7 мең сум;<br>2022 ел – 1 875 272,8* мең сум;<br>2023 ел – 1 282 280,0* мең сум;<br>2024 ел – 1 264 790,0* мең сум;<br>2025 ел – 927 828,0* мең сум.<br>*2022 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм Ярдәмче программаның гомуми финанслау күләменә кертелмәгән»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлының егерме җиденче абзацында «107» саннарын «117» саннарына алмаштырырга;

ярдәмче программаның 2 бүлегендә

1 пунктның утыз сигезенче абзацында «2018 елда» сүзләрен «2018 – 2019 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

пунктның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гомуми белем бирү оешмаларында капиталь ремонт үткәрү (шул исәптән «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында да)»;

бишенче абзацта «2018 елда» сүзләрен «2018 – 2019 елларда» сүзләренә алмаштырырга;

пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» төбәк проекты кысаларында укучыларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр формалаштыру өчен матди-техник база яңартылган белем бирү оешмалары исемлеге әлеге Ярдәмче программага 15 нче кушымтада күрсәтелде.

«Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» төбәк проекты кысаларында җайлаштырылган гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы матди-техник база яңартылган белем бирү оешмалары исемлеге әлеге Ярдәмче программага 16 нчы кушымтада күрсәтелде.»;

4 пунктның 3 таблицасында:

5 графада «2 337,51» саннарын «583,4» саннарына алмаштырырга;

асъюлда «2018» саннарын «2019» саннарына алмаштырырга;

5 пунктның егерменче абзацында «2018 елда» саннарын «2018 – 2019 елларда» саннарына алмаштырырга;

7 пунктның унөченче «2018 елда» саннарын «2018 – 2019 елларда» саннарына алмаштырырга;

8 пунктта:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен һөнәри белем алу мөмкинлеген тәэмин итү (инвалидларга инклюзив һөнәри белем бирүнең төбәк системасына ярдәм итә торган база һөнәри белем бирү оешмалары булдыру буенча чараларны финанслашу)»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2018 елда инвалидларның һөнәри белем бирү төбәк инклюзив һөнәри белем бирү системасына ярдәм итүне тәэмин итүче база һөнәри белем бирү оешмасы итеп «Чаллы педагогика көллияте» ДАҺБУ билгеләнде».

2020 елда «Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында инвалидларга һәм СМЧ затларга инклюзив урта һөнәри белем бирү төбәк системалары (алга таба – һөнәри белем бирү база оешмасы) эшләвен тәэмин итә торган база һөнәри белем бирү оешмасы төзеләчәк.

Аның эшчәнлегенең төп юнәлешләре булачак:

һөнәри юнәлеш бирү, инвалидларны һәм СМЧ затларны, аларның сәләтләрен һәм һәвәслекләрен исәпкә алып, диагностикалау һәм консультация бирү;

урта һөнәри белем бирү, һөнәри белем бирү программалары, инвалидлар һәм СМЧ кешеләр өчен өстәмә һөнәри программалар шартларын һәм тормышка ашыруны тәэмин итү;

һөнәри белем алу һәм алга таба эшкә урнашуда ярдәм итү, аларның һөнәри һәм социаль җайлашуы процессында инвалидларны һәм СМЧ затларны тәэмин итүне оештыру.

База һөнәри белем бирү оешмасын төзү нәтиҗәсендә, республикада, тулаем алганда, инвалидлар һәм СМЧ затлар тарафыннан һөнәри белем алуның архитектур һәм мәгълүмати яктан ачыклыгы дәрәҗәсе артачак. Дистанцион белем бирү технологияләрен куллану, электрон укыту өчен тернәкләндерү һәм компьютер җиһазларын үз эченә алган матди-техник һәм методик шартлар тудырылачак. Шулай ук уку-җитештерү остаханәләрендә һәм өч нозологик төркем өчен

лабораторияләрдә эш урыннары җиһазландырылачак (күрү сәләте бозылу, ишетү сәләте бозылу, терәк-хәрәкәт аппараты бозылу).»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 93 210 626,91 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 3 276 380,3мең сум;
2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;
2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;
2017 ел – 8 141 860,8 8 мең сум;
2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;
2019 ел – 16 900 942,7 мең сум;
2020 ел – 13 207 437,8 мең сум;
2021 ел – 13 185 416,7 мең сум;
2022 ел – 1 875 272,8* мең сум;
2023 ел – 1 282 280,0* мең сум;
2024 ел – 1 264 790,0* мең сум;
2025 ел – 927 828,0* мең сум.

*2022 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм Ярдәмче программаның гомуми финанслау күләменә кертелмәгән»;

5 бүлекнең таблицасындагы 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «19. | Урта һөнәри белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгән инвалидлар өлеше (узган ел белән чагыш-тырганда, процент | - | - | 101 | 102 | 103 | 105 | 107 | 109 | 11<br>1 | 113 | 115 | 117»; |

ярдәмче программага 1, 5, 8, 9, 11, 12, 13 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр);

ярдәмче программага 15, 16 нчы кушымталар өстәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин